

Кадошкино районы укытучылары ярышында  дvрт конкурсант катнашты: Латышовка гомуми урта мәктәбе башлангыч сыйныф укытучысы Р.Р. Кандралеева, Адашево урта мәктәбе  химия һәм биология укытучысы Г.Г. Полякова, Кадошкино урта мәктәбе тарих һәм жәмгыять белеме укытучысы Р.Х. Казанбаев һәм Большие Поляны топ мәктәбе рус теле һәм әдәбияты укытучысы С.Ш. Абаева.       Барлык конкурсантлар предметларын яхшы белә, сыйфатлы белем һәм тәрбия бирә; кызыклы шәхесләр, шуна жинvчеләрне билгеләv авыр булды, дип билгеләде жюри әгъза-лары. Алар барысы да ике-оч дистә эш стажлы, профессияләренә тугърылыклы укытучылар.

Ярыш барничә этаптан торды. «Мәктәп – һонәр территориясе һәм ижат киләчәге» дигәнендә укытучылар бу сvзләрнен бvгенгә актуальлеген анлатты. «Визит карточкасы» конкурсында һәрбер ярышучы педагогик һәм шәхси сыйфатларын ачты. Светлана Шәмил кызы Абаева шигырь яза икән. Аш-су остасы да. Унышларын “тамырлар агачы”на vреп кешенен vсешен кvрсәтә белvе белән залдагыларны шаккаттырды.

Рузалия  Растям кызы Кандралеева, мактаулы педагог булуы белән бергә, кул эшләре остасы. Ә Равиль Харис улы Казанбаев, профессионал тарих һәм жәмгыять белеме белгече булу белән бергә, бард жанры жырларын ярата. Үзе оста гитара колларын тибрәтә…

Менә шундый сәләтле укытучылар ярышында,  «Учитель года-2017» дә, лаеклы жинvче - Светлана Шәмил кызы Абаева (сулдан икенче). Ул Республика конкурсында катнашыр. Унышлар сезгә, Светлана ханым!